# УЧЛАРЫМДА УТЛЫ КҮМЕР

УДК 820/89(470).0
ББК 84(2Рос=Тат)-6
М98

Рәссамы НАТАЛЬЯ ГРАХАНЦЕВА
**Мөхиярова Р. Х.**

Учларымда утлы күмер: Шигырьләр.— Казан: Мәгариф, 2002.— 143 б.
ISBN 5-7761-1110-2

Мәңгелек турында уйлана алган кеше, әлбәттә, тирә-юньдәге вакыйгаларга, фани дөньяга да югарыдан, күкнең җиденче катыннан торып карый белә. Рәзинә Мөхиярның бу җыентыктагы шигырьләре дә шуның ачык бер мисалы.

**БЗ—8(67)—111—2001/2002**

ISBN 5-7761-1110-2 © «Мәгариф» нәшрияты, 2002

## ҖИЛӘКЛЕ АЛАННАР

Рәзинә — минем якташым. Ул Башкортстанның безгә күрше Чакмагыш районыннан. Туган елгабыз Базы безгә шул район аша килә. Аблай исемле авылда туып-үскән кыз, балачагы, яшьлеге һәм Базы елгасы буйлап, минем балачагым узган җиргә, үзенең максатына таба барышлый килеп чыккан. Һәм үзенең иң матур елларын уздырган.

Язмышы аны бездән дүрт-биш чакрым ераклыктагы Сикәле авылына алып килгән. Сикәле белән безнең авыл арасында бераз гына кыр һәм аннары наратлы куе урман. Балачагыбызның иң куркыныч, шомлы урыны. Биек, текә ярлар, бүре оялары. Анда кызлар аяк басмый, егетләрнең дә гаярьләре генә барып җитә. Абзыйлар бүре аулый. Кайчакларда, оядагы балаларын алып кайтып, үзебездә үстерәләр иде. Хәлбуки монысы — бүтән тарих...

Рәзинә, Сикәледә яшәгәндә, менә шунда, шул урманда җиләк җыярга яраткан.

Анда аланнар аз һәм, димәк ки, җиләк тә күп түгел. Әмма Рәзинә таба, күп таба. Шуңа күрә гаҗәпләнгән авыл халкы аңа «Урман кызы» дигән кушамат тага. Кайчак хәтта «Урман корткасы», «Урман пәрие» дип тә куялар икән.

Алансыз җирләрдә урманны келәм иткән кып-кызыл бөрлегәннәр, баланнар күңелне алгысыта. Аларны да җыймый калмагандыр Рәзинә. Җиләкләр, бөрлегәннәр, баланнар белән бергә, үзенең беренче шигырьләрен тапкандыр. Әйе, бик тә нык беләм бит: җиләкле яланнарда, язлар һәм җәйләр буе үрдәк һәм чөлдиләр әңгәмә корган күлле үзәннәрдә йөргәндә, күңелдә моң тумыйча кала димени?!

Һәм мин яшь шагыйрәнең шул төшләрдә барлыкка килгән шигъри кичерешләрен барларга тырышам, эзлим, табам һәм таныган төсле булам.

Күз алдымда — ап-ак ромашкалы җәйге алан. Бик тә, бик тә таныш. Алай гына да түгел:

> Мәтрүшкәле сихри җәйге алан,
> Йөрәгемә илһам, моңнар алам.

Сүзебезне шигырьләр раслый. Анда, карурман эчләрендә, ак каеннар үсә. Агач саен — былбыл. Кошлар телен белгән кеше алар белән серләшә ала.

Тора-бара җиләкле аланнар киңәя һәм Җир-ана рәвешле гәүдәләнә башлый. Ләкин беренче аланнар һаман иярә бара.

> Кипкән җиләк кирәк авыруыма,
> Китермәгез җансыз дарулар,—

дияр чаклар җитә.

Кипкән җиләк — җирсү дигән сагыштан дәва булырга тиештер. Хәтта әче дигән даны чыккан балан да баллы хәзер, сихәтле. Безнең урманда табылган җимешләр, азак килеп, шулай шигырьдә өлгерә.

Туган җирдән киткәч язылган әсәрләрдә күренешләр, үзләренең документальлеген саклап бетермәгән хәлдә дә, күңелдә барыбер нәкъ элеккечә яши бирәләр. Аерма шунда гына: туган як урманнары зуррак мәгънәләргә, катлаулырак вакыйгаларга тоташалар. Бер мисалда — Гаяз Исхакый язмышына катнашалар.

> Яуширмәсе — талгын бишеккәе
> Төшләренә бик еш кергәндер.
> ... Күз алдына иле килгәндер.

Шигъри фикерләр, кичерешләр дәүләт турындагы уйларга таба үсәләр. Үзенең халкын, кешеләрен утка салган, үги күргән, гөнаһсызны гөнаһларга батыра торган дәүләткә бәя бирү дәрәҗәсенә җитәләр. Аларга бүгенге яңа күренешләр өстәлә:

> Җилгә каршы кулын алга сузган
> Теләнчеләр кала утырып.

Табигатьтәге кебек, Рәзинә шигъри яланнарда да үзен иркен тота. Күпчелек очракта форма төзеклегенә аның исе дә китми кебек. Тойгыларга, тезген дигәнне белмәс хисләргә иярә. Хәтта кайчак: «Рәзинә яза алмаган берәр әйбер бар микән?» — дип тә уйлыйсы килә.

Ул — филология фәннәре кандидаты, тел белеме иясе. Шуны истә тотып: «Әгәр рөхсәт итсәләр, Рәзинә фәнни хезмәтләрен дә шигырь белән язар иде!»— дип шаяртасы килә.

Шигърияттә аның әле шундый җиңел языла торган бәхетле чагы. Тора-бара, әлбәттә, хәлләр үзгәрер, уйлар, фикерләр катлауланыр. Җаваплылык артыр. Моны ышанып әйтергә була, чөнки аның инде хәзер үк төгәл фикергә, нык кысага сыйган шигырьләре, бигрәк тә кыска шигырьләре, шулай уйларга мөмкинлек бирә. Кызыксынган кеше шагыйрәнең «Кит», «Көт», «Кал» дигән шигырьләрен укып карасын. Болар иң нечкә зәвыклы укучы да гаеп таба алмаслык төгәл әйтелгән фикерләр түгелмени?!

Кит!..
Җаның минем янда кала бит.

Таныш хисләр шулай шигъри табыш дәрәҗәсенә ирешә.

Шагыйрә безне киләчәктә дә шушындый табышлар, ачышлар белән сөендерә алыр әле, дигән өметтә калам. Җиләкле яланнарга бетми торган матурлык, иминлек телим.

*Әхсән Баянов, 2001*

## ТӘРӘЗӘМНЕ АЧАМ...

Тәрәзәмне ачам һәр көн саен,
Сафлык, пакьлек өйгә керсен, дип.
Бөтерелеп усал җилләр исә,
Менә, безне инде күрсен, дип.

Тәрәзәмне ачам һәр көн саен,
Иртәнге саф һава керсен, дип.
Тузан, туфрак әрсезләнеп керә,
Безнең барлыкны да белсен, дип.

Тәрәзәмне ачам һәр көн саен,
Кояш нуры килеп керсен, дип.
Шомландырып болыт каплый аны,
Сабыр гына көтеп торсын, дип.

Тәрәзәмне ачам һәр көн саен,
Гел яхшылык өйгә керсен, дип.
Ишетелә сыман зур Галәмнән:
«Дөнья болганган чак, түз син!» — дип.

## МЕҢ КАТ ЯНАРСЫҢ

Күкләрдән иңгән сихри хисләрне
Саклыйсым килә, яклыйсым килә.
Гөнаһлы Җирнең гади кешесе,
Мәхәббәтемне таплыйсың, тимә!

Мәхәббәт уты чистартсын әле
Җаның-тәнеңне соң чиккә кадәр.
Мең кат янарсың, мең кат көярсең
Башыңны иеп килгәнгә кадәр.

## ГАШЫЙК КҮЗЛӘР

Гашыйк күзләр белән
Карасаң дөньяга,
Җылынып китәдер
Бу салкын дөнья да.

Яратудан көчле
Тойгы бармы икән?!
Хисләрне чикләүче
Ярлар тармы икән?!

Бар Галәм елмая
Гашыйклар йөзендә.

Күңелләр яшәрә
Кышын да, көзен дә.

## АЗАН

Гасырлардан ишетелгән кебек
Күңелемдә яңгырый бу азан.
Тетрәнүле халык тарихының
Моң-сагышы мәллә, син кайдан?

Йөрәкләрне шомландыра кебек
Ишетелгән саен бу азан.
Дөньядагы барлык мөселманның
Кан-яшеме әллә, син кайдан?

Ишетүгә тораташтай катам,
Тылсым көче синдә, и азан!
Гади сүз дә, гади моң да түгел,
Күкләрдәнме әллә, син кайдан?

Изгеләрдән изге, и азан!

## БИРНӘ

Җәйнең матур
Мизгелләрен:
Матурлыгын,
Нәфислеген,
Җылылыгын,
Җайлылыгын
Салыйм күңел
Сандыгыма.
Бирнә булып
Барсын әйдә
Күзләремә,
Кышларыма.
Бик күңелсез
Чакларында
Сандыгымны
Ачып куеп
Сокланырмын
Җәйдә җыйган
Байлыгымның
Барлыгына.

## ҖӘЙГЕ АЛАН

Ап-ак ромашкалы җәйге алан,
Җанга, тәнгә синнән сихәт алам.

Мәтрүшкәле сихри җәйге алан,
Йөрәгемә илһам, моңнар алам.

Кызыл җиләк тулы җәйге алан,
Кышкы чиллә өчен дару алам.

Җиләк һәм чәчәкле җәйге алан,
Күзем һәм кышыма көч-дәрт алам.

## ТУҢДЫМ ИНДЕ...

Туңдым инде Җирдә җылы тапмый,
Башкаларны гына җылытып.
Ярый әле, күктә Кояш балкый,
Ныклап бозга әйләнүдән саклый.

Җылытырга килдем Җир йөзенә,
Һәм шулай ук җылы алырга.

Җылытучы газиз кеше тапмый,
Чәчләремне инде ак бәс каплый.

## КАШКАРЫЙЛАР

Җәй азагы. Чәчәк атты
Бакчамда Кашкарыйлар.
Аллы-гөлле чәчәкләрем
Гел кояшка карыйлар,
Чәчкәйләрен тарыйлар.

Җылы җитми җаннарына
Талпыныр көннәрендә.
Соңлап аткан чәчәкләрнең
Чыкмый бит өннәре дә.
Авыр ла көннәре дә.

Сабыр гына, тыныч кына
Балкыйлар Кашкарыйлар.
Бердәнбер чын мәхәббәтен
Көтә-көтә арыйлар,
Чыдам шул Кашкарыйлар.

## ЯШЬЛЕГЕМ

*Белми калдым, сизми калдым*
*Яшь гомернең узганын.*
Татар халык җыры

Яшьлегем минем кайда калды дип,
Агымсулардан кат-кат сорадым.
Әллә ашыктым, әллә соңладым,—
Яшьлек үткәнен соңлап аңладым.

Карап каласы иде дә аны,
Күрми дә сизми ахры калганмын.
Яшьлегем төсе итеп җаныма
Юлга тынгысыз йөрәк алганмын.

Җырда җырланган яшьлегем үткән,
Дип искәртәләр инде бик күптән.
Үтсә үткәндер, кем гаепле соң?
Күрми калганмын, көткәнгә күктән...

## УРАМНАРДА КИПКӘН ЯФРАК ИСЕ

*Көзләрдән соң язлар килми,*
*Алда салкын ак кышлар.*
Равил Фәйзуллин

Купшы киеменә төренгән дә,
Кәс-кәс атлап килә матур көз.
Матурлыгы бер хәл, әче җиле
Үзәкләргә үтә, ләкин түз.
Урамнарда кипкән яфрак исе,
Күңелемдә һаман язлар хисе.
Алтын көзләрнең дә гомерләре
Артык озын түгел, үтә тиз.
Җилгә очкан яфракларны саныйм,
«Туктагыз! — дим.— Кая китәсез?»
Урамнарда кипкән яфрак исе,
Күңелемдә һаман язлар хисе.

## САГЫШ ГАЗАБЫ ДА НАЗЛЫДЫР

Туктап тормый тормыш, алга бара,
Сөйдең ни дә аңа, сөймәдең.
Мизгелләре һаман үтеп тора,
Көйдең ни дә аңа, көймәдең.

Беразга да туктап тормый тормыш,
Әле табыш, әле югалыш.
Инде таптым, диеп йөргән чакта
Алда имтиханнар — сыналыш.

Югалтмыйча, сынатмыйча яшәү
Бәндәләргә бер дә язмыйдыр.
Тормыш шулай корылганга микән
Сагыш газабы да назлыдыр.

## БЕЗНЕҢ ДӘҮЛӘТ

Җир шарында
Безнең илдәй,
Намуслыны
Бер почмакка
Кыса торган,
Изеп, сытып
Үтә торган,
Яраларга
Учлап-учлап
Тоз тутырган,
Бүтән илне
Кешелек соң
Белә микән?

Рәнҗеш алган,
Каһәрләнгән,
Кешеләрен
Утка салган,
Кимсеттергән,
Үгисеткән,
Угры иткән,
Чарасыздан
Гөнаһсызны
Гөнаһларга
Батыра торган
Башка дәүләт
Җир йөзендә
Бармы икән?!

## И ҖИР ШАРЫ...

И Җир шары...
Галәмнең бер планетасы.
Яшеллеккә, матурлыкка
Таң калырлык бер ноктасы.

И Җир шары...
Тиңсез Галәмнең уртасы,
Яшәешнең умырткасы,
Мәхәббәт-гыйшык томкасы.

И Җир шары...
Кешелекнең син вөҗданы.
Адәм дигән бөек затның
Сынаулардан торган җаны.

И Җир шары...

## БАР БАЙЛЫГЫМ...

Таш пулатлар салдырмадым
Төягемдә.
Бар байлыгым күңелемдә,
Йөрәгемдә.

Яшәешкә дан, мәдхиям —
Күзләремдә.
Табигатьне яратуым —
Йөзләремдә.

Бар байлыгым дөньялыкта —
Яратуым,
Якын кешеләрем өчен
Җан атуым.

## ТЕЛӘНЧЕЛӘР

Исеп уза җилләр талгын гына,
Ак карларның чәчен сыпырып.
Җилгә каршы кулын алга сузган
Теләнчеләр кала утырып.

Көн-таң атса, шәһәр урамында
Сукбай, хәерчеләр күбәя.
Яңгырдан соң үскән гөмбә кебек,
Теләнчеләр рәте киңәя.

Хәерчеләр тулган урамнарда
Байлар тоя микән бәхетне?
Тынгы тапмас беркем мондый илдә,
Булган очракта да тәхетле.

## КАРА ЛА ГЫНА УРМАН

Кара ла гына урман эчләрендә
Яктырыбрак китә аланнар.
Йөрәгемәниләр булды икән,
Тынгы белми шушы аралар.

Кара ла гына урман эчләрендә
Үсә микән ап-ак каеннар.
Кошлар сайрый агачларга кунып,
Былбыллары агач саен бар.

Кара ла гына урман эчләрендә
Озак йөрдем инде каңгырып.
Ниләр күрми адәм башлары, дип,
Карап калды урман, кайгырып.

## МӘСКӘҮ ЯГЫ

Чүпкә баткан Рәсәй башкаласы,
Вокзалларың аша күз салыйм.
Хатын-кызны җиккән арбаларга
Күзләремне талдырып карыйм.

Хатын-кызның җилкәсендә кебек
Рәсәйдәге тормыш-кормышлар.
Бер иңенә ничә капчык аскан,
Төшкән төсле авыр каргышлар.

Рәсәй дөньясының каргышларын
Хатын-кызлар йөртә иңнәрдә.
Рәссам Репин бурлаклары сыман —

Өметсезлек, сыкрау йөзләрдә.

Чүпкә баткан Рәсәй башкаласы
Түрәләрең бүләк өләшә.
Соңгы тиеннәрен саный-саный,
Гади халык хәер бүлешә.

## ТҮЗЕП БУЛМЫЙ

Түзеп булмый
Хаксызлыкны күргән чакта.
Эндәшмәсәм, яктылыкны
Күреп булмый.

Түзеп булмый,
Чәчрәп чыгам, ярсыйм, ташам.
Су болганчык, тыныч кына
Йөзеп булмый.

Түзеп булмый,
Ялганчылар күз буяса,
Ялган эшне иләкләрдән
Сөзеп булмый.

Түзеп булмый
Оятсызлык, явызлыкка,
Барсына да түзсәм әгәр,
Үзем булмыйм.

## ЯЗ ҖИТКӘНЕН ШУННАН БЕЛӘМ

Гөрләвекләр җырлап ага,
Кояш нурлары бага.
Гөрләвекләргә карасам,
Балачак канат кага.

Гөрләвекләр тавышында
Кызлар көлүләре бар.
Ярсый-ярсый ашыгалар,
Әйтерсең юллары тар.

Челтер-челтер агып китте,
Кемнеңдер балачагы,
Гөрләвекле шушы язын
Юк инде табачагы.

## СӘЕР АЙЛАР... МАЙ АЙЛАРЫ

Әллә нинди быел май айлары,
Салкын җилле, карлы, яңгырлы.
Йөрәкләргә үтеп калтырата
Салкын җиле, кары, яңгыры.

Әллә нинди быел май айлары,
Күңел өши, җаным дерелди,
Әйтерсең лә урман эчләрендә
Ялгыз калган кошчык черелди.

Әллә нинди быел май айлары,
Җанны өшеттерә салкыны,
Ымсындыра янар учак булып,
Йөрәкләргә күчми ялкыны.

## ТЫҢЛА ӘЛЕ

Тыңла әле, әнә миләш сөйли,
Әллә сөйли, әллә көйләр көйли.
Ботакларын җимеш аска сөйри,
Тәлгәшләрдә утлы күмер көйри.

Тыңла әле, миләш ниләр сөйли,
Юк, сөйләми, матур бер көй көйли.
Җил-музыкант никтер аны сөйми,
Миләш җимешләре яна, дөрли.

Тыңла әле, миләш нидер сөйли,
Яраткан бер көен һаман көйли.
Көзге кичләр яфракларын саный,
Миләш инде хәзер янмый, көйми.

## МОҢЫМ БЕЛӘН БӘХЕТЛЕМЕН

Бу кадәрле моңлы түгел идем,
Моң дәрьясы бара агызып,
Яр читенә чыгып баса алмыйм,
Моң дулкыны ала каерып.

Айкый-чайкый моңнар күңелемне,
Бөртек кадәр кере калмастыр.
Җырга-моңга гашыйк күңелемнең
Канатлары бер дә талмастыр.

«Моңлы бала бәхетсез була»,— дип
Халык нигә шулай әйткәндер?
Моңсыз бала, бәлки, бәхетсездер,
Моңы шуңа ташлап киткәндер.

Ник бәхетсез булсын моңлы бала?!
Аның моңы бәхет түгелме?!
Ташлама син мине, моң дәрьясы,
Дулкыннарда айка күңелне!

Моңсыз гына ничек яшәрмен соң?!
Күңелемне нәрсә тутырыр?
Ялгыш кына читкә каксаң мине,
Йөрәгемә юшкын утырыр.

Моңым белән бәхетлемен Җирдә
Сагыш тулы җанда, моң тулы.
Җырларымны тезәм ап-ак җепкә,
Сандугачлар табар бу юлы.

Табарлар да, алсу таң атканда
Көйгә салып җырым җырларлар.
Сизгер җаннар җәйге иртәләрдә
Моңнарымны минем тыңларлар.

## КАЙЧАГЫНДА...

Кешеләрне аңлау өчен
Кайвакытта гомер китә.
Кайчагында... тутырып бер
Күзләренә карау да җитә.

Кешеләрне аңлау өчен
Күпме тоз ашалып бетә.
Кайчагында... читтән генә
Күреп калу — шул да җитә.

Кешеләрне аңлау өчен
Көннәр үтә, еллар китә.
Кайчагында... сирәк кенә,
Бер сөйләшү — шул да җитә.

## ҖИР-АНАКАЙ, КИЧЕР БАЛАҢНЫ!

Гөнаһларым хәтсез җыелгандыр,
Җир-Анакай, кичер балаңны!
Тетрәнүләр бер-бер артлы килә,
Алардан соң сабак аламмы?!

Туры юлдан атларга да телим,
Юллары бит бигрәк буталчык.
Туп-турыга барган чагымда да,
Тәгәримен, ясап мәтәлчек.

Сөрлегүләр күпме булды инде,
Күпме булды сагыш, үкенү.
Тырмашканда тормыш дәрьясында
Аз булмады табыш, үсенү.

Гөнаһларым хәтсез җыелгандыр,
Җир-Анакай, кичер балаңны!
Үксез итмә, ташлама син мине,
Күрсәт бәхет тулы аланны.

Җир-Анакай, кичер балаңны!

ЯЛТЫРАП КИТТЕ УРАК

Күз җитте дип йөрәк сыкрый,
Күздә күпме матурлык!
Саргылт яшел келәмендә
Колач җәеп ятарлык.

Күзнең күркәмлеге үзгә,
Аңлаганы аңларлык.
Көзгә адым ясаучының
Күңеле тулы байлык.

Көзләр диеп тибә йөрәк,
Тибә йөрәк кызурак.
Ал шәфәкъ кызыллыгында
Ялтырап китте урак.

ХӘБӘРЛӘРЕҢ КӨТЕП

Язмышымнан сине куып,
Йөрәгемнән исемең сызып,
Ярсу хисләремнән туеп,
Күңелемнән алып ташлавым,
Дигән булып үзем юанам.
Җанкаема урын тапмый,
Тормышымны аклый-таплый,
Хәбәрләрең көтеп яшәвем.

ЯНСАҢ — ЯН!

Пыскып янган учагыма
Көтмәгәндә җилләр иste.
Ялкынланды, учак дөрли,
Утлар хисләремне чиште.

Онытканмын, учагымда
Утыннары аз калганын.
Сагышланып карап торам
Соңгы кисәкләр янганын.

Янсаң — ян соң, азаккача,
Очкынланып шашып-шашып.
Янар өчен туган җаннар

Яна бит ул, күккә ашып.

## ӨМЕТ ИТӘМ

Таң атуга, һәр көн сине көтәм,
Килер юлың ничә кабат үтәм.
Юлларыңа сөю гөле тезеп,
Толымнарым үреп, тагын сүтәм.

Кич җитүгә, һәр көн саен көтәм,
Офыкларга кадәр барып җитәм.
Сагынуга түзеп тора алмас,
Килер әле бер, дип өмет итәм.

## УЙЛЫЙСЫҢ, УЙЛАНЫРСЫҢ...

Уйлыйсың, барыбер уйлыйсың
Очрашу минутын ничә кат.
Кабатлый алмассың мәңгегә
Илаһи мизгелне, итмә ант.

Тәкәббер холкыңны каһәрләп,
Уйларсың барысын да мең кабат.
Йөрәгең туктаусыз кычкырыр:
«Яраттым, яраттым!» — дип набат.

Очраклы очрашу булмады,
Җаннарның тартышы бу халәт.
Язмышка язылган күрешү,
Укыма туктаусыз гел нәләт.

Уйлыйсың, барыбер уйлыйсың,
Сызсаң да хәтердән тырышып.
Вакытлар үткәч тә сагынып
Яшәрсең, күңлеңдә күрешеп.

## ТАЛ АГАЧЫ

Тал агачы...
Гап-гади бер
Агач кебек.
Бөдрәләре
Суга ятып
Сыйпый күбек.

Тал агачы
Тыйнак кына
Агач кебек.
Күзләреннән
Агым суга
Төшә керфек.

Тал агачы
Эндәшми дә
Тора кебек.
Тик судагы
Бар серләрне
Күрә кебек.
Тал агачы
Бар серләрне
Күрә кебек.
Чәчләренә
Барысын-барысын
Үрә кебек.

## КИПКӘН ҖИЛӘК

Кипкән җиләк кирәк авыруыма,
Китермәгез җансыз дарулар.
Туган якта үскән бер җиләктән
Бетәр кебек сырхау, арулар.

Кипкән җиләк кирәк авыруыма,
Үз авылымда гына кипкәне.
Еракта да синнән шифа көтә,
Читкә күптән чыгып киткәне.

САГЫШ

Сагыш...
Тормышымда таныш,
Кирәкми бу агыш,
Килгәнсеңдер ялгыш.
Әйтмә: «Мин, дип, язмыш!»
Бәхилләш, кит, сагыш.
Алларыңда табыш,
Шатлык илә ярыш,
Салкын җилгә карыш,
Бәхет белән кавыш,
Моң-зарлардан калыш,
Ишеттеңме, сагыш?
Синнән китеп барыш.
БЕЛМИМ, НИГӘ?!

Җаным өзгәләнә,
Җаным телгәләнә,
Җаным бәргәләнә,
Белмим, нигә?!

Күпме өзгәләнер,
Күпме телгәләнер,
Күпме бәргәләнер —
Беләм димә!

Өзгәләнгән җаным,
Телгәләнгән җаным,
Бәргәләнгән җаным
Сиңа нигә?!

# Е

Тәрәзә белән көзге —
Хатын-кызның юл башы.
Тәрәзә һәм көзгегә
Күпме сеңгән күз яше?!
ӘЙТСӘЛӘР-СОРАСАЛАР...

Мәхәббәт ни була, дисәләр,
Мин синең исемеңне атармын.
Сөюең җылытып торганда,
Кышын да гел чәчәк атармын.

Мәхәббәт ни була, дисәләр,
Мин синең күзләргә карармын.
Очкыннар нур сибеп торганда,
Бәхетле йолдызлар санармын.

Мәхәббәт ни була, дисәләр,
Мин сине йөрәктә тоярмын.

Йөрәктән йөрәккә агылган
Нурларым дөньяга коярмын.

ЯРАТАМ

*Бер генә сүз белә минем йөрәк,*
*Бу сүзне кем аңа өйрәткән?*
*Һәр тибеше белән кабатлана,*
*Китми бер сүз, китми йөрәктән:*
*—Яратам, яратам...*

Әхсән Баянов

«Яратам, яратам, яратам»,— дип,
Йөрәк, какма әле шулчаклы.
Акылыңа кил син, ник дулыйсың,
Җаным-тәнем гел синең яклы.

Син искәртеп торгангамы, белмим,
Һаман бер сүз генә кабатлыйм.
Башка сүзләр кая югалгандыр,
«Яратам»,— дип әйтәм кат-кат мин.

БАРМА УРМАННАРГА...

Урманнарга кабат барма син,
Йөрәгеңә яра алма син,
Бергә йөргән сукмакларга карап,
Җаннарыңны утка салма син.

Үзәгемне саксыз өзмә син,
Күзләремдә минем йөзмә син.
Бер тутырып кына карыймчы, дип
Тынычлыгым минем бозма син.

Юлларыма инде чыкма син,
Сүзләремне минем екма син.
Хисләрем һич кенә сүрелми, дип
Алларымда минем чүкмә син.

ЕЛМАЮЫМ КАЛСЫН

Күңелеңә щатлык булып керим,
Моң-сагышы калсын үземдә.
Татар хатыннары сабыр булган,
Сабыр булган гомер-гомергә.

Җанкаеңа шифа булып керим,
Яралары калсын үземдә.
Күз алдыңда булсын елмаюым,
Елмаюым калсын йөземдә.

# I

Күзләр әле үтмәсә дә,
Урамда кар исләре,
Уемда кыш төсләре.

Күктә йөзә карлы болыт,
Күкләрдә кар исләре,
Кардай актыр хисләрем.

Беренче карны көткәндә,
Сукмакта кар исләре,
Энже кардай хисләрем.

## КОШЛАР МИНЕМ СӨЮ ҖЫРЫН ҖЫРЛЫЙ

Тагын үтеп китте Җирдә бер көн,
Синсез үтте, сине сагынып.
Кошлар миннән сәлам әйтә микән,
Яннарыңнан үтсә кагынып?

Ә мин һәр көн очкан кошлар аша
Сәламемне сиңа дип юллыйм.
Кошлар минем сөю җырын җырлый,
Берәр ишетерсең дип юрыйм.

## СӨЮ

*Кем әйтә сөю ләззәт дип,*
*Дөресе, сөю — газап.*
Саҗидә Сөләйманова

Әйе, дөрес, сөю — газап.
Газапның да ниндие:
Сагышларга төренгәне,
Тетрәүләрдән торганы,
Сагынудан, саргаюдан
Акыллар җуйдырганы.

Йөрәкләрне учка кысып,
Түздерәлмәс булганы.
Парә-парә телгәләнеп,
Кайнап-кайнап тулганы.

Бер — күкләргә күтәргәне,
Кабат җиргә куйганы.
Җир белән күк арасында
Адашудан туйганы.

Ялкыннарда дөрли-дөрли
Көл булганчы янганы.
Ул газапка түзмәс идең —
Язмышка язылганы...

## КҮРСЕН ӘЛЕ...

Хисләремне җырга салыйм әле,
Моңлы итеп җырлап алыйм әле.
Әрнү-газапларым көйгә төреп,
Энҗе күңел белән калыйм әле.

Хисләремне гөлгә күмим әле,
Күңел җылым белән түлим әле.
Яратуым моңлы көйгә күчеп,
Чәчәк теле белән сөйлим әле.

Хисләремне офык күрсен әле,
Алсу такыялар үрсен әле,
Шәфәкъләргә күтәрелеп карап,
Изге мәхәббәтем белсен әле.

## ГАСАБИЛЫ ГАЗАП

Гасабилы газап. Җәзалыйсың,
Парә-парә телеп күңелем.
Ни гаебем булсын инде минем?! —
Таш йөрәкле кеше түгелмен.

Сөю ялкыныннан эреп киттем,
Кай арада, белмим үзем дә.
Дөрләп утта янам, газапланам,

Йөрәк әле ярый түзем дә.

Гасабилы газап, син күпкәме,
Күктән җибәрелгән сынаумы?
Күзәтәсең, бәлки: нишләр икән,
Түзәр микән, әллә сынармы?

Сыну җиңел, түземлекләр кирәк,
Сыналырга диеп килгәнмен.
Таллар җиргә бөгелгәнне күреп,
Мәхәббәткә башым игәнмен.

## КАЛЫР КЕМДЕР...

Бу дөньяда мин кемгәдер кирәк кебек,
Тормыш җебен шуңа гына барам үреп.
Җиргә басып, кеше булып йөргән чакта
Эзләремә берәү карап калыр, күреп.
Хисләремне чәчми саклый алыр төреп.

Бу дөньяда мин кемгәдер кирәк кебек,
Күзләрем дә шуңа гына карый көлеп.
Тормыш җебем кинәт кенә өзелгәндә,
Карап калыр микән берәү миңа, сөеп,
Мин киткәнгә сыкрап, җаны-тәне көеп?

## ӘЛЛӘ КҮРДЕМ,
## ӘЛЛӘ КҮРМӘДЕМ ДӘ...

Әллә күрдем, әллә күрмәдем дә,
Әллә сөйдем, әллә сөймәдем.
Өермәдәй хисләремне туплап,
Ак яулыкка төреп төйнәдем.

Каты итеп ныклап бәйләдем дә,
Карап торам хәзер аптырап.
Хис төрелгән ап-ак төенчеккә
Күз яшьләрем тама ялтырап.

## АЧЫ БАЛАН АЧЫ ТҮГЕЛ

Баланнарны ачы диеп
Күпме шигырь, җыр туган.
Көзнең суыкларыннанмы
Аңа бал тәме тулган.

Суыгын да исләмәгән,
Җилләрдә бөрешмәгән.
Ачы балан ачы түгел,
Язмышка бирешмәгән.

Салкын көзнең кичләрендә,
Тирбәлә җилдә балан.
Тормышлар әчеләнгәндә,
Баланнан мин көч алам.

## ЯКТЫЛЫКТАН ТУЯ АЛМАМ

...Хәлләрең ничек? — дигәнгә,
Җавапларым гел әзер;
Каш җыерып йөрү авыр,
«Ал да гөл!» — димен хәзер.

Йөрәгемдә ут булса да,

Ялкыннарын чыгармыйм.
Янам-көям, ни булса да,
Түзәм әле, чыдам мин.

Якыннарны, дус-ишләрне
Зарлар белән күммимен.
Ак төсләрне табып яшим,
Караларын күрмимен.

Читтән карап торган уйлар:
Бәхеткә чумдым инде,
Туганда ук күлмәк киеп
Тугандай, уңдым инде.

Бу дөньяның матурлыгын
Күрергә дип туганмын.
Һәр мизгелгә, һәрбер таңга
Соклanудан туймамын.

«Бөгеләм, менә сынам...» — дип
Йөргәндә дә тураям.
Йа Ходаем, ярдәмең бир,—
Яктылыктан туя алмам...

## НИЯТЛӘГӘН ХӘЯТ

И, Галәмнең серле Җир кешесе,
Ничәмә юл, сынау каршыңда.
Мизгел саен алышына дөнья,
Нинди уйлар килә башыңа?

Ак-карасы кинәт аерылмый,
Адым саен кирәк сайларга.
Гамәлләрең, фикерләрең барла —
Алып китәр алар кайларга?

Сикәлтәләр, каршылыклар ерып,
Дөрес юлдан бару бик авыр.
Гел турыга атлый алмый кеше,
Кайчагында көтә бик сабыр.

Өметләнеп көтә, салкын җилләр
Басылырлар, диеп, ниһаять.
Тыныч кына яшәү бирелмәгән,
Шулай ниятләгән бу хәят.

## ТЕЛӘК

Карт әбиләр өйрәтәләр иде:
«Теләк телә, балам, телә!» — дип.
Алар сүзе күңелемә сеңгән,
Һәр көн саен теләк телим бит.
Күзләремне ачып җибәрүгә,
Илгә-көнгә телим иминлек.

Йөрәгемә яра Җир шарында
Барган сугыш, ачлык, тетрәүләр.
Тынычлан, дип, Җиребезне сыйпыйм,
Кемгә кирәк андый күкрәүләр?
Күзләремне ачып җибәрүгә,
Илгә-көнгә телим иминлек.

Һәр кешегә матур тормыш телим,
Дөньялыкка шуңа килгәнбез.
Бары сөю, татулыклар белән

Җир йөзендә көчле икән без.
Күзләремне ачып җибәрүгә,
Илгә-көнгә телим иминлек...

## АП-АК КЫНА...

Туган якка кыш та килде,
Кар-бураннар сөенде.
Агач, куак — бөтен җирләр
Ак күлмәктән киенде.

Ап-ак кына, йомшак кына,
Йомшак кына, пакь кенә.
Яңа яуган кар өстеннән
Бер кыз килә сак кына.

Җылы якка китми калган,
Чыдам кошлар җим эзли.
Күрше йортка кайткан кызны,
Авыл егете күзли.

Тәрәзәләр бизәкләнгән:
Кыш бабайның һөнәре.
Шәһәр кызы суга бара,
Күз тимәсен, күр әле!

## УТЛЫ КҮМЕР

Чәчелмәсен диеп очкыннары
Утлы күмер кыстым кулыма.
Утлы күмер булып җанга кердең,
Каян килдең гомер юлыма?!

Мин ташлый да алмыйм ул күмерне,
Көлләре дә әле күренми.
Уч төбемдә утлы күмер йөртәм,
Дөрләп тора, сүнми, сүрелми.

## ЯРАТ МИНЕ

Ярат мине,
Сагышларым,
Борчуларым
Тарат инде.

Ярат мине,
Һәр мизгелдә
Күзләреңә
Карат инде.

Ярат мине,
Көземдә дә
Гашыйк итче
Кабат мине.

## КЫШКЫ КОЯШ

Кышкы кояш
Сүрән генә
Елмая да,
Моңсуланып,
Җиргә карап
Торган була,
Харап кына
Булмасаңчы,
Дигән кебек,

Нык борчылып,
Маңгаен да
Җыергалап,
Көрсенгәндәй
Итеп куя.

# F

Җәйнең шундый кыска июнь төне,
Йокы кунмый керфек очына.
Әллә йөрәк, әллә акыл уяу —
Өмет итә бәхет кошына.

## ТАҢ ҖИЛЕ

Исемеңне әйттем әкрен генә,
Таң җилләре мине тыңлады.
Күңелем сиңа шул таң җиле аша
Ераклардан сәлам юллады.

Җитез җилкәй очты синең якка,
Сәламемне минем кыстырып.
Түземсезлек белән җавап көтәм
«Мин монда!» — дип дәшәм кычкырып.

Таң җиле шул үз вакытын белә,
Минем аһ-зарларга карамый.
Һәр көн саен бары иртән исә —
Көндез вә кич аңа ярамый.

Таң җиле ул — сабыр, тыйнак, тугры,
Башкаларга бер дә кушылмый.
«Сәламеңә каршы сәлам килде,
Кабул итче!..» — диеп пышылдый...

## ГАҖӘПЛӘНӘМ

Гаҗәпләнәм барысын белгән бәндәләргә,
Өйрәнергә бернәрсә дә тапмаганга.
Бар нәрсә дә ап-ачык дип масайганга,
Һәрвакытта үзен-үзе аклаганга.

Гаҗәпләнәм уйланмаган бәндәләргә,
Битарафлык пәрдәләре барлыгына.
Җир-суларны җансыз диеп белгәннәргә,
Күңелләрнең шундый да нык тарлыгына.

Гаҗәпләнәм артык салкын бәндәләргә,
Дөнья җылылыгын тапмый йөргәннәргә.
Янмый-көйми, яндырмыйча-көйдермичә,
Кабык белән үзен үзе төргәннәргә.

Гаҗәпләнәм артык тыныч бәндәләргә,
Гамьсез, уйсыз, сүзсез гомер сөргәннәргә.
Зур җиһанны сизми-тоймый, аңламыйча,
Алдындагын гына бары күргәннәргә.

## ЗИРАТ

Юл буенча кала зират —
Мәңгелек йорт ишегалды.
Җан — мәңгелек, тән — каласы,
Туфрак эче ышыгырак.

Кисәткәндәй хаталарны,
Гомерләрнең кыскалыгын,

Шомлы тынлык каршы ала,
Шомлы тынлык кыса тынны.

Юл буенча кала зират,
Исән-сау йөргәнне теләп.
Билгесезлек алларына
Кем китсен соң үзе теләп.

## САРЫ ЯФРАК

Тезелешкән каен яфраклары,
Сары яфраклары бирешкән.
Сагыш төсен күрмим агачларда,
Кояш белән алар бер иштән.

Сары яфраклары арасыннан
Кояш нуры уйный качышлы.
Сары яфрак — ул кечкенә кояш,
Минем өчен бу да ачыштыр.

## АПА!..

*Апа, апа, дөрес яздыммы?*
*Әйтегез инде, Сез бит — апа!*

(Педагогик практика вакытында
укучым әйткән сүз.)

Чын татар мәктәпләрендә
Укытучы ул — апа.
Авырлыклар башка төшсә,
Укытучы юата.

Апа диеп, матур итеп,
Сүз кушалар балалар.
Өметләнеп, иркәләнеп,
Күзгә карап калалар.

Матур йола, күркәм гадәт
Апа диеп эндәшү.
Укытучы узып китте,
Карап калдым көнләшеп.

## БУЛМЫЙДЫР УЛ КИТЕП...

Туган ягын кем ташласын инде,
Ташлап түгел, яклап китәләр.
Китәр идемени асыл ирләр?
Китәргә бит мәҗбүр итәләр.

Гаяз Исхакыйлар киткән димә,
Китмәгән ул, нишләп китсен ди?!
Күңеле калган аның Яуширмәдә,
Тәнем кире анда кайтсын дип.

Мөһәҗирлек язмышкае язган,
Язмышлардан юктыр узмышлар.
Кая барып, кайда гомер итми
Бу татарлар, ай-һай, тормышлар.

Яуширмәсе — талгын бишеккәе
Төшләренә бик еш кергәндер.
Чит илләрдә солтан булганда да
Күз алдына иле килгәндер.

Җәсәде бит калды чит җирләрдә,
Җаны — Урал-Идел ярында.
Туган ягын кем ташласын инде,

Өзелеп сөйгән халкы барында?!

ТАНЫМАДЫҢ

Алларыңнан үтеп киттем,
Танымадың син мине.
Танып үзең килсәң әгәр,
Танымамын мин сине.

ЕЛЛАР САНЫЙМ

Көзләр җитсә, еллар саныйм,
Саный-саный артка карыйм.
Алдан саныйм, арттан саныйм,
Буталам да, тагын саныйм.

Язлар белән санаргамы?
Көздән артка карагамы?
Кышын саныйм, җәен саныйм,
Әллә айлап санаргамы?

Көзләр җитсә, еллар саныйм,
Сагышларым алып карыйм.
Аен саныйм, көнен саныйм,
Ник санарга, алга барыйм...

O

Урмандагы карагайлар
Гел пышылдап сөйлиләр.
Гасырлардан безгә күчкән
Моңлы бер җыр көйлиләр.

X

Галәмдә һәр кеше —
Бер тузан иңлеге.
Ә күңел эчендә —
Галәмнәр киңлеге.

9

Юк белән бар янәшә килсә,
Юк-бар белән генә яшибез.
Барлы-юклы кыска гомерләрне
Аяк асларына түшибез.

>

Туу-үлү арасында
Ничә чакрым юллар бар?
Гомер юлы кемгә — бик киң,
Кем өчендер — артык тар.

В

Шатлык килә —
Иңгә канат куя.
Килә кайгы —
Кеше аңын җуя.

I

Язмышым да минем катлы-катлы,
Юлларым да никтер бик чатлы.
Гел турыга гына бармаганга,
Кыйнамачы, дөнья, бу чаклы!

ӘНИ КҮЧТӘНӘЧЕ

Күчтәнәчкә әни май җибәргән,
Түм-түгәрәк — аймы, кояшмы?!
Әни җибәргәнгә күрә микән,
Күчтәнәче аның кояшлы.

Күчтәнәчтән миңа ишетелә
Әниемнең назлы сүзләре.
Карап тора сыман, сагышланып,
Күпне күргән уйчан күзләре.

Түм-түгәрәк итеп бу ак майны
Кулларында әни йөгерткән.
Кул эзләрен майга салып куеп,
Имзалагандыр чын йөрәктән.

Күчтәнәчең, әни, бигрәк тәмле,
Балачагым дигән илдәнме?
Күз нурларың әллә, шунда күчеп,
Кул эзләрең аша килгәнме?

Күчтәнәчкә әни май җибәргән,
Туган ягын искә алсын, дип.
Туган якның басу-кырлары да
Күңеленә кереп калсын, дип.

Күчтәнәчкә әни май җибәргән,
Түм-түгәрәк — аймы, кояшмы?!
Әни җибәргәнгә күрә микән,
Күчтәнәче аның кояшлы...

ЭНДӘШ МИҢА

Эндәш миңа
Мәгърур тауның
Кайтавазы
Кебек кенә.

Елгаларның
Агышлары
Ярга каккан
Тавыш белән.

Чишмәләрнең
Челтер-челтер
Саф сулары
Аккан кебек.

Җитез җилләр
Сызгыруы,
Сызлануы
Сыман итеп.

Яңгырларның
Тамчылары
Җирне кочып
Үпкән төсле.

Җәйге давыл
Чәчәкләрне
Ярсый-ярсый
Кочкан төсле.

Йә булмаса
Эндәш миңа,
Эндәш миңа
Үзең булып,
Яратуым кабатланыр,
Онытылып,
Онытылып...

## РӘНҖЕМӘ!

Рәнҗемә, күңелем, рәнҗемә!
Өзелмә, үзәгем, өзелмә!
Түгелмә, күз яшем, түгелмә!
Аларга ул лаек түгел дә!
Рәнҗемә, өзелмә, түгелмә!

## КИТ

Кит...
Әйтмәм синсез яши алмыйм дип.

Кит!..
Җаның минем янда кала бит.

## КӨТ

Көт...
Сиңа иярергә тырышам ич.

Көт...
Арып-талып кире кайтам кич.

Көт!..
Куып җитеп булмый сине һич.

## КАЛ

Кал...
Йөрәгеңдә булса булыр кар.

Кал...
Эретергә карың хисем бар.

Кал..
Хисләр кушылганда өйләр тар.

Кал!..
Минем өчен генә туган яр...

## КӨЗ СУЛЫШЫ

Көз сулышы күптән җирдә, күктә,
агымсуда.
Вакыт! Сиңа тотынырга теләп
очам шунда.

Табигатьне кичектереп, ашыктырып
булмый,
Җылы җәйләр нинди озын булсын,
күңел туймый.

Көз бикәсе ашыга-ашыга
ишек шакый,
Ашыкмаска, көз артыннан җилләр
карлар ташый.

Табигатьтә көзләр: алышына
тирә-яклар,
Язга чаклы сулар, үсемлекләр
тыныч йоклар.

## ЮЛГА ЧЫКТЫМ

Юлга чыктым, бик-бик озын юлга,
Көчем җитәр микән озакка.
Авырлыгын, шатлыкларын төяп,
Барып кермәм микән тозакка.

Әй, буталчык, кызык фани дөнья,
Мең төрлегә кайчак әйләнә.
Күңелем югарыда оча кебек,
Аякларым җиргә бәйләнә.

Дөньясыннан күңел кайта кайчак,
Аннан тагын барысы җайлана.
Изгелек тә әле бетмәгән, дип,
Йөрәк ничәнче кат җанлана.

Кул селтәргә теләк булганда да
Күңел никтер һаман алдана.
Күпме күрдем: яхшы, яманын да,
Тормыш, мине бик еш алдама!

Чыдамлыгым кабат-кабат сынау,
Белмим инде, нигә кирәктер?
Мин бит әле һаман талчыбыктай,
Мондый сабырлыклар сирәктер.

Әй син, фани дөнья, җир тормышы,
Ничәнче кат инде уфтанам.
Уфтансам да, китмим әле синнән,
Яратуларыма юк чамам.

## БӘБИ, КЫЗЫЙ, ӘНИ, ӘБИ

Бәби, кызый, әни, әби —
Мамыктай йомшак сүзләр.
Җиһанның бар ягыннан да
Сезгә текәлгән күзләр.

Сез — дөньяның, яшәешнең
Иң беренче тоткасы.
Ир-егетләр өчен дә сез —
Бер таяну ноктасы.

Бәби, кызый, әни, әби —
Иң гүзәл, күркәм затлар.
Шушы гүзәл затлар Җирдә
Кешелеклек хакын саклар.

## ЮЛЛАР

*Юллар, юллар, инде ничә еллар*
*Аерыла алмыйм сездән мин.*
Әхмәт Ерикәй

Юллар, юллар, тормыш дәрьясында
Бихисап сез, саны юк сыман.
Һәрберегез яңа һәм дә үзгә,
Әллә шуңа һәрчак юксынам.

Һәрбер юлга озак итеп җыям
Уем, хисем, кирәк эшләрем.
Юлым үткәч, тагын барлап куям
Һәр мизгелем, кичерешләрем.

Юллар, юллар, сезгә өмет баглап,
Ничәнче кат инде җыенам.
Тагын көчем, дәрт-дәрманым артыр,
Кайткан кебек зур бер җыеннан.

## ДУСЛАР КИРӘК

Йөрәгеңдә утлар янса,
Әйтер сүзең күп җыелса,
Уртаклашыр дуслар кирәк!

Абынганда, сөрлеккәндә,
Алҗыганда, талчыкканда
Таянырга дуслар кирәк!

Яраларың ачылганда,
Әрни-әрни авыртканда,
Юатырга дуслар кирәк!

Шатлыкларың ташып чыкса,
Уңышлардан баш әйләнсә,
Алмаштырмас дуслар кирәк!

Бәхетле көннәр булса да,
Караңгы төннәр булса да,
Ни булса да — дуслар кирәк!

## ШИГЫРЬЛӘР

Күңелемне минем аклар өчен,
Йөрәгемне минем саклар өчен
Диеп кенә туа шигырьләр.

Озын юлда миңа иптәш булып,
Ак-караны аерыр чиктәш булып
Туа бугай кайчак шигырьләр.

Бу җанымны Җирдә тотар өчен,
Хыялларым Күктә очар өчен
Туа ахры, туа шигырьләр.

## КӨЙ АГЫШЫ

Көй агышы...

Ә без икәү
Тирбәләбез
Моңсу гына

Бер халәттә.

Көй агышы...

Әйләнәбез
Әллә өйдә,
Әллә күктә
Җир тирәли.

Көй агышы...

Онытылды
Тирә-якта
Барысы-барысы —
Без бер кеше.

Көй агышы...

Без очабыз,
Тиңсез Галәм,
Синең янга,—
Кабул итсәң,

Моң-көйләрдә
Дөньяларын
Онытучы
Бу җаннарны...

## ШӘМДӘЛЛӘРДӘ УТЛАР...

Шәмдәлләрдә янган ут янында
Кемнәр өчен җырлар язасың?!
Үткән гомереңне уйлый-уйлый,
Йокылардан әллә язасың?

Шәмдәлләрдә утлар яна... яна!
Әнә, таң да инде сызыла.
Шәмдәлләрнең нуры тоныклана,
Көн яктысы аңа сузыла.

Шәмдәлләрдә утлар... Син дә шулай
Шәмнәр кебек сызып янасың.
Шәмдәлләрдә янган ут янында
Кемгә атап җырлар язасың?

## ГАСЫР БАШЫ, ГАСЫР АЗАГЫ...

*Шаулый диңгез...*
*Җил өрәдер...*
*Җилкәнен киргән кораб!*
*Төн вә көндез*
*Ул йөрәдер:*
*Юл бара ят ил карап...*
Дәрдмәнд

Җиргә кеше
Килгәнгә дә
Байтак икән.
Егерменче
Гасырларның
Азагына
Кораб җиткән.
Уалырмы,

Югалырмы
Олы кораб
Зилзиләдә,
Әллә балкыр
Өр-яңадан
Яңа гасыр
Диңгезендә?
Кораб йөзә...
Төялгәннәр
Иманлысы,
Имансызы.
Ишетергә
Вакыттыр да
Һәммәсенә
Иман сүзе.
Кораб китә
Зур диңгезгә.
Уң ягыннан
Кояш карый.
Сул ягыннан,
Ачуланып,
Җилләр яный.

КИЕК КАЗ ЮЛЫ

Тулган айга карап торгангамы,
Күңелем мөлдерәмә тулы.
Җирдә юллар бихисап булса да,
Ымсындыра Киек Каз Юлы.

Ымсындыра Киек Казлар Юлы,
Кулын сузган төсле күренә.
Мин — Җир кызы, ә йолдызлар никтер
Гомер буе йөрәк түрендә.
ШУЛАЙ ЯРАТАМ

Йөрәк моңга тулгач, нишлим инде,
Моңнарымны җиргә таратам.
Ул моңнарым чәчәк, гөлгә күчә,
Матурлыкны шундый яратам.

Йөрәк моңга чумгач, нишлим инде,
Моңнарымны куам, таратам.
Сагыш-газап, әрнү кичерсәм дә,
Фани дөнья, сине яратам.

Йөрәк моңлы булгач, нишлим инде,
Моң-дәрьялар аша җан атам.
Янам, көям, очкынланам, шашам,
Дөньяны мин шулай яратам.
ХАТЫН-КЫЗНЫҢ
ЯШЕН СОРАМЫЙЛАР

Хатын-кызның яшен сорамыйлар,
Унсигездә генә йөрәге.
Җаннар алмашуын тоя белә,
Җир-Ананың ул бит терәге.

Хатын-кызның яшен сорамыйлар,
Хатын-кыз ул — һәрчак Алиһә!
Матурлыгын күреп калыйм диеп,
Һәр таң саен назлы җил исә.

Хатын-кызның яшен сорамыйлар,
Ак чәчләре — акыл билгесе.
Битләрендә әз-мәз үзгәрешләр
Мәңгелек ут — кояш тимгеле.

ДИҢГЕЗ

Җилләр, җилләр җилфер-җилфер
Чәчләремне тарады.
Зәңгәр күктән, күзен кысып,
Кояш миңа карады.

Суларыңда, зәңгәр диңгез,
Чәчләремне чылаттым.
Зәңгәр күзләреңә карап,
Сагышымны тараттым.

Дулкыннарың ник бәрәсең,
Ярларыңа сугылып.
Йөрәгемне ярсытасың,
Китәсең дә кагылып.

Әй диңгез, зәп-зәңгәр диңгез,
Шундый тирән, шундый киң.
Күпме җирләрне гизсәм дә,
Булмас кебек сиңа тиң.
АГЫМСУ

*Агышың, и агымсу, туп-тулы зар,*
*Синең ни хәсрәтең, ни моңнарың бар?*
Дәрдмәнд

Бар хәсрәтне, сагыш-моңны
Агымсуга салабыз.
Агып китсә, кире кайтмас,
Диеп җырлап алабыз.

Агымсу агып китә дә,
Яңадан урап кайта.
Гасырларның хәсрәтләрен,
Сагыш-моңын тарата.

Агымсулар ага, ага,
Ярлары монда кала.
Быелгы агымсуларга
Кемнәр хәсрәт-моң сала?!
ТАУЛАР

Таулар, таулар,
Таш кыялы таулар...
Күпме күргән яулар?!
Тетрәнгәндә
Кыялардан,
Күз яшьләре булып,
Сулар аккан
Кайчагында
Күргәннәре,
Нәфрәт булып,
Йөрәгендә каткан.
Түзәрлеге
Калмаганда
Вулканнарын
Күккә аткан.
Таулар... таулар...

## ӘЙТМӘГЕЗЧЕ ЮАТЫР СҮЗ

Юллар озын, шома түгел,
Ташлары да җитәрлек.
Әйләнеп артка карасаң,
Ис-акылың китәрлек.

Таянырга терәк тапмый,
Таллардай бөгеләмен.
Әйтмәгезче юатыр сүз,
Чишмәдәй түгеләмен.

Атлыйм әле салмак кына,
Алдыма карап кына.
Күрәсемне күрәм инде,
Язмышка ярап кына....

## БЕРЕНЧЕ КЫРАУ

Йөрәгем ачтым —
Сере калмады.
Көзге кыраулар
Аны алмады.

Күпме газаплар
Чыныктыргандыр.
Кырау алдында
Тынып торгандыр.

Беренче кырау —
Чирканыч алдым.
Мәңгелек утка
Йөрәгем салдым.

## ИКЕ ДӨНЬЯ АРАСЫ

Бу ике дөньяларның арасын
Мизгеле дә икән хәл итә.
Китәсеңме, әллә каласыңмы,
Озаклама, вакыт тиз үтә.

Шулай кинәт... бер дә уйламыйча,
Ярты-йорты кала эшләрем.
Болай кинәт кенә китеп барсам,
Борчылырлар якын кешеләрем.

Ничә секунд икән тарткалаштык,
Китү... калу, дөнья хакында.
«Калыйм»,— дидем, «әле китмим»,— дидем,
Әйтер өчен бардыр хакым да.

Теге дөньяларга күчүләрне
Мизгеле дә хәл итә микән?
Ашыктырмасагыз иде мине,
Җирдә эшем ай-һай күп икән.

## БӨДРӘ ТАЛЫМ

Су эчендә, бөдрә талым,
Тирбәләсең тын гына.
Гашыйк җаннар, сине күреп,
Илһамлана, нур ала.

Берьялгызың су эчендә
Боегасың, сизәмен.
Су эчендә нигә калдың
Өзелмиме үзәгең?

Җирдәге бар ваклыклардан
Читләшәме йөрәгең.
Сулардагы дулкыннарны
Җиңүдәме теләгең?

Нечкә билле бөдрә талым,
Җилләргә бөгеләсең.
Бөгеләсең, иеләсең,
Ничек сынмый түзәсең?

## КИПКӘН БУКЕТ

Чәнечкеле булсын, кипкән булсын,
Әллә ничә айлар үткән булсын.
Калдырыгыз миңа ул букетны,
Күңелемә нурын биреп торсын.

Чәнечкеле булсын, кипкән булсын,
Кышның урталары җиткән булсын.
Өстәлемә куйыйм ул букетны,
Туган ягым истәлеге торсын.

Чәнечкеле булсын, кипкән булсын,
Матурлыгы инде киткән булсын.
Җан өшеткеч кышкы бураннарда
Җылы җәйне сагындырып торсын —
Чәнечкеле булсын, кипкән булсын...

## ӘБИЛӘР ЧУАГЫ

Әбиләр чуагы соңлады,
Кемнеңдер гозерен тыңлады.
Көзнең нәкъ уртасын җиткереп,
Көтелгән вакытлар чыңлады.

Әбиләр чуагы соңлады,
Кемгәдер мәхәббәт юллады.
Көттереп, өздереп, көйдереп,
Соңарган матур җыр җырлады.

Әбиләр чуагы соңлады,
Сәбәбен беркем дә белмәде.
Җенләнеп дөньяны куганнар
Алтындай бу чорны күрмәде.

## САБЫРМЫ СОҢ ЙӨРӘК?

«Сабырлыклар сары алтын»,— диләр,
Сары алтын никтер күренми.
Гомер буйларына сабыр итәм,
Кулым алтыннарга күмелми.

«Сабырлыклар сары алтын»,— диләр,
Сабыр, сабыр, дия акылым.
Йөрәк кенә кая сикерәдер,
Өзелгәндер тагын бер кылым.

## БЫЕЛГЫ ЯЗЛАРНЫҢ ШАУКЫМЫ

Булдылар язларның төрлесе:
Суыгы, җылысы, ләйсәне.
Йөрәктә каладыр бары тик
Барысыннан җыелган сәйләне.

Булдылар язларның төрлесе,
Күңелем шатлана, сөенә.
Барчасы тормышым тавына
Җыела, куела, өелә.

Булдылар язларның төрлесе:
Караттым, яраттым, сагындым.
Сөюдән талпынып, үрелеп,
Аккоштай канатым кагындым.

Булдылар язларның төрлесе,
Гомернең язлары каулады.
Быелгы язларның шаукымы
Җанымның күгендә шаулады.

## КҮТӘРАЛГАН КАДӘР

Хисләр дулкынына утырам да,
Иңләп йөзәм күңлем диңгезен.
Йөрәгемә бәрә ярсу дулкын,
Нидә икән сәбәп, нигезе?!

Кичерешләр, каршылыклар белән
Атлап барам, бик еш тукталам.
Нинди төсләр, күпме гамәл җирдә?!
Матурлыкка гына укталам.

Һәр көн саен борчу-сагыш баса,
Күңел иләгеннән үткәрәм.
Җәрәхәтле йөрәгемә салып,
Күтәралган кадәр күтәрәм.

## ЗАМАНА

Ваклана,
Таплана,
Пычрана
Кеше җаны
Замана тузанында.
Тузаннарны
Кага-кага
Күренмичә
Калына
Гомерләр узганы да.

## БАКЧА

Бакча. Тып-тын. Бары кош тавышы
Назлый-назлый җанны иркәли.
Баш очымда аяз күк йөзендә,
Нурын түгә кояш иртәли.

Агач яфраклары, пышылдашып,
Хәерле көн тели җиһанга.
Үләннәрдә әнә чык тамчысы
Күзен кыса җәйге томанга.

Яланаяк бакча буйлап йөрим,
Дәва эзләп ярсу күңелгә.
Агач, үлән, кояш җылысыннан
Моң-сагышлар җиргә күмелә.

## САГЫШ...

Таныш, бик тә таныш,
Килгәнсеңдер ялгыш,
Әйтмә: «Мин, дип, язмыш!»
Бәхилләш, кит, сагыш.

Бәхет белән кавыш,
Моң-зарлардан калыш.
Ишеттеңме, сагыш?!

## КАЗЛАР КИТТЕ...

Нидер сөйләп, моңлы көйләр көйләп,
Йорт казлары үтте тезелеп.
Күзләр җиткәнлеге искә төште,
Йөрәктә кыл төште өзелеп.

Кыйгак-кыйгак диеп, салмак кына
Ап-ак казлар үтте тезелеп.
Соңгы көннәренең җиткәнлеген
Йөри микән алар сизенеп.

Ап-ак мамыкларын юрган итеп,
Казлар бара елга буйлатып.
Кошларның да язмышлары ачы,
Китте алар йөрәк дулатып.

## КҮЛ ЙӨРӘГЕ

Кышкы салкыннарны көтә бугай,
Күл йөрәге сыкрый, калтырый.
Күлнең моңсу күкрәгенә ятып,
Көзге моңсу кояш ялтырый.

Тынып калган күлнең тирә-ягы,
Шом урала аяк астына.
Яңгыратып бер җырлыйсы килә,
Моң таралыр иде чак кына.

## КАР ИСЕ

Әле бит яумаган,
Әле бит еракта
Ак карлар, пакь карлар.
Исләре тарала,
Ап-аяз һавага...
...Офыклар карала —
Җыена яварга...
...Яз-җәйне оныттам,
Күңелне җилкетә,
Йөрәкне оета
Яумаган кар исе...

## БУЛМАДЫ...

Сулкылдап елыйсым килде,
Сулкылдамадым гына.
Кычкырып җырлыйсым килде,
Җырлый алмадым гына.

Диңгездә йөзәсем килде,
Йөзә алмадым гына.
Күкләргә очасым килде,
Оча алмадым гына.

Өзелеп сөясем килде,
Сөя алмадым гына.
Шул турыда язармын, дидем,—
Яза алмадым гына.

## ҖАНЫМ ҺАМАН УНҖИДЕДӘ

Язлар килә, китә, аңардан соң
Җәе, көзе, кышы... агалар.

Һәр ел саен язгы кояш көлә,
Кулын болгап, еллар калалар.

Ә минем җан һаман унҗидедә,
Шулай булыр гомер-гомергә.
Картаелмас ничә яшь булса да,
Йөрәк әйләнсә дә күмергә.
БАРЫ ТИК ТИҢ ИТКӘНГӘ...

*Язмышларны*
*Күңел күзе аша үткәрергә —*
*Шигъриятькә килә хатыннар.*
Саҗидә Сөләйманова

Шигъриятькә күпләп килә
Хатын-кыз — нәфис затлар.
Сәбәпләрен кем белсен соң,
Ни әйтерләр ир-атлар?!

Ә мин менә шулай уйлыйм:
Язмышларны, ялгышларны
Иңнәрендә йөрткәнгә,
Колаклары «Сөям!» дигән
Тылсымлы сүз көткәнгә;

Тормышның авырлыклары
Үзәгенә үткәнгә,
Ничә еллар көткән бәхет
Күренмичә киткәнгә;

Җир-Ананың сызлануын
Үз сызлавы иткәнгә,
Тормыш йомгагын да җырлап,
Авырсынмый сүткәнгә,—
Һәм, әлбәттә, шигъриятне
Үзенә тиң иткәнгә...

•

Февраль киче. Зәп-зәңгәрдән һава.
Каен зәңгәр шәлен ябынган.
Сирәк-мирәк йолдыз күктән карый,
Кемгә, диеп, нәрсә язылган.

Язмыш дәфтәремне алдан укып,
Төзәтәсе килә кайчакта.
Ялгыш юлдан атлап китмәс идем,
Фәрештәләр, сез соң кай чатта?!

Зәңгәр шәл ябынган каен кызы,
Күлмәк итәкләре ак кына.
Кичке зәңгәрлектән илһам алып,
Күңелемә салдым чак кына.

O

Шәһәр йоклый, ак карларга чумып,
Песнәкләр туй итә, агачларга кунып.

Шундый тыныч кына ак кар ява,
Ни өчендер, сыкрап, минем йөрәк яна.

Шәһәр йоклый, гамьсез бер тынлыкка чумып,Карап торам тәрәзәдән, күңлем тулып.

ШӘМ ЯКТЫСЫ

Караңгылык иңгән бер бүлмәдә
Шәм яктысы сибә нурларын.
Юлчы килә, шул яктыга карап,
Алга таба сузып кулларын.

Күк гөмбәзен каплый болыт-юрган,
Йолдыз да юк, хәтта ае да.
Төн карасын ерып, берәү атлый,
Җилләр төрле якка каера.

Әле ярый, алда шәм яктысы,
Кулын болгап, аңа эндәшә.
Юлчы йөзе кинәт нурланганга
Төн патшасы гына көнләшә.

# Х

Кыр казының һаваларда
Озын юллар сызар вакытлары.
Йөрәкләрнең, урыныннан кубып,
Сыкрап-сыкрап сызар вакытлары.

Кыр казының һаваларда
Кыйгачлатып очар вакытлары.
Күңелләрдә, көзге күккә карап,
Өметләрне кочар вакытлары.

СЫЗДЫРЫП ТАРТ ӘЛЕ КУРАЕҢНЫ

Сыздырып тарт әле кураеңны,
Дөньяларга моңнар агылсын.
Күңел ишекләре аша кереп,
Хисебезгә килеп кагылсын.

Сыздырып тарт әле кураеңны,
Кошлар тыңлап, алар тын калсын.
Моң дәрьясы, Галәмнәрне гизеп,
Якты уй-хисләргә уралсын.

Ничә буын аша килеп җиткән,
Ерак юллар үткән бу курай.
Сагышлының сагышларын җилгә
Очыргандыр ничә кат шулай.

Сыздырып тарт әле кураеңны,
Моңы бары моңга күмелсен.
Йөрәкләргә үтеп керә алгач,
Гади генә бер моң түгел син.

УЙ

Уй...
Хисләремне чикләмәче, куй.
Уй...
Йөрәгемә бары чәчәк уй.
Уй...
Күз алдымда һаман синең буй.
Уй...
Күңелемә пәрдә корып куй.

СЫНМАДЫМ

Сындырырга теләделәр —
Сынмадым.
Акны кара, диюләргә
Күнмәдем.

Түзмәс инде йөрәк, диеп
Уйладым.
Сабырлыкка өйрәнүдән
Туймадым.

Дөнья йөген тартып барып
Армадым,
Начарлыкка, яманлыкка
Бармадым.

## МОҢ

Заманнарның усал җилен кисеп,
Ходай Җиргә моң да тараткан.
Таралган да, шушы сихри аваз
Моңлыларны үзенә караткан.

Ярый әле, Җирдә моң да яши,
Кайгы-сагышларны күтәреп.
Ярый әле, моң чишмәсе яши,
Моңсызларның исен китәреп.

Моңнар ташый язгы ташкыннардай,
Ашкыныплар куя йөрәкләр.
Кайчак моңнар көзге яңгыр төсле,
Тып-тып итеп тибә күкрәкләр.

Тукталмасын Җирдә моң ташкыны,
Яусын карлар, яңгырлар булып.
Колакларда, йөрәкләрдә чыңлап,
Кала моңнан күңелләр тулып.

## КЫШКЫ УРМАН

Ап-ак вак-вак сәйлән төсле
Карлар ява.
Наратларның очларында
Энҗе яна.

Урман әкияттәй сихри
Карга чумган.
Агачларны иркәләүче
Нурлар тулган.

Килгән кош та, җәннәт диеп,
Монда очып.
Кышкы урман сәлам бирде,
Мине кочып.

## ЯЗЛАР САЕН

Язлар саен
Күңел көтә.
Язлар саен
Йөрәк — көлтә.
Кояш, нуры
Төшү белән,
Шул көлтәгә
Утлар төртә.

I

Бу дөньяда үкенүләр азмы икән?
Үкенүсез яшәүләрне язмый икән.

В

Табар өчен югалтабыз,
Дигән булып юатабыз.

F

Кояш булмаганда,
Ай да нинди якты.
Күзге аяз төндә
Бирәү учак якты.

X

Кышкы иртә. Офыкларда зәңгәр пәрдә.
Иртәләгән юлчы ап-ак карга карый.
Сәхәргә дип торучылар намаз укый,
Юлчыларга изге сәфәр юрый-юрый.

O

Карурманнарда —
Халык моңнары.
Ничә гасырлар
Күкләр тыңлады.

•

Караңгыдан яктылыкны
Ничә еллар эзләдең.

Алда бер очкын күренгәч,
Шатлыгыңа түзмәдең.

В

Карап  калдым эзләреңә,
Яшь килгәнче күзләремә.
Бәхет телим юлларыңа,
Дисбе тотып кулларыма.

СИБЕЛДЕ ЧӘЧЛӘРЕМ

*Сибелә чәчләр юллар кичкәндә.*
Илдар Юзеев

Сибелде чәчләрем, сибелде,
Юлларга энҗеләр тезелде.

Бер сүттем, бер үрдем чәчләрем,
Үргәндә, сүткәндә өзелде.

Өзелде чәчләрем, өзелде,
Толымнар калдылар юкарып.
Иң куе тарак — чор төбендә
Калдылар чәчләрем йолкынып.

Йолкынды чәчләрем, йолкынды,
Аптырап торамын кайвакыт.
Сибелә чәчләрем юлларда,
Ашыга, көтми бит, һай, вакыт.

## ЮК ИНДЕ...

Күзләреңә бөтен Галәм сыйган:
Зәңгәр күк тә, яшел алан да.
Челтер-челтер агып яткан чишмә,
Җәйрәп яткан тиңсез ялан да.

Күзләреңнән бөре исе аңкый,
Ул күзләрдән килә яз исе.
Ул күзләрдә илһам чыганагы,
Ул күзләрдә сөю, наз иле.

Ул күзләрең төпсез диңгез сыман,
Чумсаң, кире чыгу — икеле.
Күпме күрмәмешкә салышсам да,
Котылулар миңа юк инде.

## ХАТЛАР ЮЛЛЫЙМ

Җырлый-җырлый бакчаларда йөреп,
Гөлләр арасыннан сине эзлим.
Җыр тибрәткән гүзәл чәчәк аша
Синең шаян күзләреңне күзлим.
Эзлим-эзлим, инде күптән эзлим,
Бертуктамый күзләреңне күзлим.

Җырлый-җырлый урманнарны гизеп,
Аланнарда туктап-туктап уйлыйм.
Уй ташкыннарында сине күрәм,
Карый-карый һаман күреп туймыйм.
Уйлыйм-уйлыйм, инде күптән уйлыйм,
Уйлар ташкынында күреп туймыйм.

Җырлый-җырлый кош очканны карап,
Кош артыннан сиңа сәлам юллыйм.
Очкан кош та сине танып алыр,
Каурый-каурый хатлар сиңа юллыйм.
Юллыйм-юллыйм, инде күптән юллыйм,
Кош каурыен хатлар итеп юрыйм.

## ТӨНГЕ ТЫНЛЫК

Төнге тынлык...
Йөрәгемне тыңлыйм,
Сине уйлап туймыйм.

Төнге тынлык...
Йолдызларга карыйм,
Уйларымны тарыйм.

Төнге тынлык...
Сихри айны күзлим,
Сагынуларга түзим.

## ҖАНЫМ ТЫНЫЧ ТҮГЕЛ

Җаным тыныч түгел, анысын беләм,
Йөрәгем буш түгел, анысын тоям.
Күңел кошым әллә кайда сайрый,
Шуңа микән, димен, янам-көям.

Җаным тыныч түгел, анысын аңлыйм,
Йөрәк тыныч түгел, анысын сизәм.
Янган утка үзем барып кердем,
Янсам янам, димен, әмма түзәм.

## ТУЙ КӨННӘРЕ

Туй көннәре...
Һәр ел саен кабатлана
Уй көннәре...

Туй көннәре...
Инде ничә еллар үтте...
Ай, көннәре...

Туй көннәре...
Утырам ялгызым өйдә,
Һай, көннәре.

Туй көннәре...
Йөрәгендә белмим кемдер,
Вай, көннәре...

## НӘРКИС ЧӘЧӘК

Нәркис никтер соңлап чәчәк атты,
Соңлады шул, бик нык соңлады.
Ләлә чәчәк коя, ә нәркиснең
Йөрәгендә сөю чыңлады.

Чын ярату аның күңелендә
Ни өчендер соңлап уянды.
Кинәт кенә дөрләп кабынды да,
Йөрәгендә балкып ут янды.

Нәркис яна хәзер ут эчендә,
Мәхәббәте бигрәк соңлады.
Янып сүнгән моңсу ләлә чәчәк
Аһ-зарларын аның тыңлады.

## НИШЛӘРСЕҢ?

Әйтмә миңа бер сүз,
Янам-көям синсез.
Илаһи көч миндә,
Мәхәббәтем тиңсез.

Китмә миннән бик тиз,
Үкенерсең чиксез.
Күзләреңдә сөю,
Син нишләрсең минсез?

## БӘЛКИ...

Җилдән җитез канатларым булса,
Очар идем сезнең якларга.
Чәчләреңнән сыйпап узар идем,
Дулкынланып алар тузар иде.

Кояш нуры булсам, шат елмаеп
Төшәр идем керфек очыңа.

Сине үбеп, күккә ашар идем,
Нурга чумып, янә качар идем.

Яңгыр булсам, җылы ташкын булып
Юар идем барлык газабың.
Битләреңнән сөеп үтәр идем,
Бер карашың миңа җитәр иде,
Бәлки, бәхетле дә итәр иде.

## ЯЗМЫШ БЕЛӘН УЙНАМА

Күзләремне талдыра,
Карашларың яндыра.
Сихерле күз сирпүләрең
Юлларымнан яздыра.

Күңелемне сынама,
Җаным синсез кыйнала.
Язмышыма язылгандыр,
Язмыш белән уйнама.

Сабырлыгым сындырма,
Йөрәгемне яндырма.
Синнән башка яши алмыйм,
Үзеңнән дә калдырма.

## КИТТЕҢ...

Киттең...
Тормыш ярларында
Карап калдым.
Мәңге төзәлмәслек
Яра алдым.

Киттең...
Җанда ут чәчәге
Балкый янып.
Таҗларыннан энҗе
Төшә тамып.

Киттең...
Газапларын үзем
Беләм татып.
Эрегән күңел тагын
Калды катып.

## СИХРИ ОЧКЫН

Көтмәгәндә очкын чәчрәп,
Йөрәгемә кадалды.
Бер очкыннан, ялкын ялмап,
Тынычлыгымны алды.

Сихри очкын каян килгән,
Күкләрдәнме, җирдәнме?
Йөрәктәге боз катламын
Эретерме, җиңәрме?

Сихри очкын йөрәгемдә
Озаккамы, күпкәме?
Күрешүләр кайчан икән?
Әллә бары күктәме?

## БАЛАЧАК

Балачак...
Кулларын сузучы
Бәләкәй бер кызчык
Нәрсәдер дәшкәндәй —

Кичәге рәшәдәй.

Балачак...
Алларда зур диңгез,
Чиге юк, ул чиксез,
Суы саф, бер керсез —
Корабта илләр гиз.

Балачак...
Ак хыял илендә
Канатлар куелган
Ялкынлы хисләргә —
Хәзер дә исләрдә.

## ЭЗЛӘДЕМ

Әрнегән җаныма дәвалар тапмыйча,
Галәмнән мин сине эзләдем.
Болытлар артыннан елмайган кояштай,
Нур сипте гел көләч йөзләрең.

Сагыштан интегеп, дәвалар тапмыйча,
Мин сине ничә ел эзләдем.
Шифалы яңгырдай яудылар туктамый
Ягымлы, исерткеч сүзләрең.

Ярсыган йөрәккә дәвалар тапмыйча,
Күпмеләр мин сине эзләдем.
Йолдыздай нур бирә тормышым юлына
Сихерле яп-якты күзләрең.

## СУЛАР ТЫНДЫЛАР БУГАЙ

Ярсу елга ташып чыкса,
Эзе кала ярларда.
Йөрәктә дә дулкын эзе,
Онытылмый ярлар да.

«Онытма!» — дип әйтмәсәң дә,
Онытылмас шикелле.
Онытырга тырышсам да,
Онытуым икеле.

Язын ташкан елгаларда
Сулар тындылар бугай.
Күңелдәге ташкыннарны
Тыңлый моңланып тугай.

## САГЫНУНЫҢ ЧИГЕ БУЛА МИКӘН?!

Сагынуның чиге була микән?!
Сагынуларга түзеп була микән?!
Сагынуның соңгы мизгелендә
Сагынудан ярлар тула микән?!

Сагынуымны ничек аңлатырга?!
Сагышымны ничек таратырга?!
Сагынуларга түзә алмаганда,
Сагыныр ярны ник каратырга!
Сагыныр ярны ник яратырга!

## ЯҢГЫР ИСЕ

Җир яшәрә тагы, җир шатлана,
Язлар җиткән икән, язлар җиткән.
Гөрләвекләр күптән агып киткән,
Кошлар шат җырларын җырлый икән,
Җирдә яңгыр исе, яңгыр исе,
Кытыклана җанда сөю хисе.

Җирнең өстен болыт-юрган япкан,
Тылсым-юрган инде килеп җиткән.
Шифалы су ераклардан икән,
Юындырам дигән уйда микән?
Җирдә яңгыр исе, яңгыр исе,
Кытыклана җанда сөю хисе.

Болыт, җир тартыла бер-беренә,
Сабырлыкның инде чиге җиткән.
Җир күкрәге — таулар еш-еш сулый,
Түземлекләр бетте диеп уйлый,
Җирдә яңгыр исе, яңгыр исе,
Кытыклана җанда сөю хисе.

## I

Белсәң иде
Сине ничек сагынуым,
Киткән якларыңа карап табынуым,
Күз алдымда назлы карашыңны тоеп,
Шул очкыннан дөрли-дөрли кабынуым,
Тигез юлда кинәт кенә абынуым.

## B

Күпме газап чигәремне белсәм,
Юлларыңа чыкмас идем лә.
Йөрәгемә урын таба алмыйм,
Мәхәббәткә башым идем дә.

Илаһи хис — яратуны данлап,
Бәргәләнә йөрәк, бичара.
Юкка гына җырламыйлар икән,
Сагынуга, диеп, юк чара.

## >

Кил, өшегән җаныңны мин җылытырмын,
Кайнар хисем бишегендә тирбәтермен.
Күңелем каткан инде диеп миннән китмә,
Үрсәләнгән гашыйк җанны мәхрүм итмә.

## 9

Төн карасы ерып, күңелемә
Ак нур булып килеп керәсең.
Ташкыннардай ярсу хисләремне
Йөрәк пәрдәң белән төрәсең.

Тыпырчынам, синең йөрәгеңнән
Чыгып китәр өчен юл эзләп.
Аның саен ныграк ябышам мин,
Булмый, булмый хисем томалап.

БАРЫБЕР ЯРАТЫРСЫҢ

Син бит мине барыбер яратырсың,
Яратмыйча мөмкин түгелдер.
Ничә еллар җыйган хис чиләгем
Синең алларыңда түгелде.

Түгелде дә, миңа буйсынмыйча,
Хис томаны безне чолгады.
Сабырлыгым, җитдилегем шулчак:
«Сау бул!»— диеп, кулын болгады.

Үрелделәр хисләр талчыбыкка
Уралгандай оҗмах гөлләре.
Тал бөгелә җилләр искән саен,
Ник сагышлы икән күзләрен?!

# Е

Күңелемә моңнар булып кердең,
Йөрәгемә такыялар үрдең,
Нигә диеп инде мине күрдең?!

Сагышларым хәзер кая куйыйм,
Йөрәгемне кай җиреннән уйыйм,
Исемеңне йөрәгемнән җуйыйм?!

ОНЫТТЫҢМЫ?

Онытгыңмы?
Әллә йөрәгемнең
Тибешләре хәзер иштелми?!
Табышмактай булды синең җаның,
Тылсым-сүзләргә дә чишелми.

Оныттыңмы?
Назлы карашларым
Күзләреңне ничек иркәли!
Һәр көн саен җилләр сәлам ташый,
Кояш чыгу белән, иртәли.

Оныттыңмы?
Болытларга качып,
Яңгыр булып сине юганым.
Йөрәгеңә тамган тамчыларны
Яратуым диеп юрадым.

Оныттыңмы?
Чык тамчысы булып,
Сиңа күзем кысып калганым.
Бар табигать сине миндәй назлый,
Галәмнәрдән сөю алганмын.
Оныттыңмы?..

КИЛЕРЕҢНЕ КӨТТЕМ

Килереңне көттем гомер буе,
Йөрәгемдә урын сакладым.
Авыр чаклар булды, сынатмадым,
Хисләремне җилдән яклaдым.

Тау-ташны да җимерер вулкан булып
Хисем ташый, ташый чарасыз.
Күңелемдә чыңлый соңлаган җыр,
Буламыни сөю ярасыз?!

Гомер буе көткән мәхәббәтем
Сагыш күлмәгенә төренгән.
Сагышларың — чәчәк гөлләмәсе
Күңелемә нигә үрелгән?!

## КОЯШ БУЛЫП НУРГА ЧУМАР ИДЕМ

Болытларга менеп китәр идем,
Болыт эчләрендә син булсаң.
Яңгыр булып җиргә явар идем,
Яңгыр тамчысына сыйдырсаң.

Төн җитүгә айга менәр идем,
Уең белән Айга менә алсаң.
Тотынышып Айда йөрер идек,
Төшләреңдә мине күрә алсаң.

Кояш сыман нурым чәчәр идем,
Кояш нурларында коенсаң.
Иркәләнер идем чәчләреңдә,
Ул нурларны мин дип тоялсаң.

## СИНСЕЗ КӨЯМ

Челләләрдә янган йөрәк
Чыдый, түзә, билләһи.
Түзмәс иде, минем йөрәк —
Керсез, бөек, илаһи.

Яна ла ул ялкынланып,
Мәңгелек ут шикелле.
Сүндерергә көчем җитми,
Ут ягучым сөйкемле.

Челләләрдә җаным көя,
Синсез көям, күрмисең.
Тормыш фәрманнары кырыс —
Чәчең чәчкә үрмисең.

## КӨТӘМ

Көтәм...
Сызылып алсу таң атуын,
Кояшымның назлы балкуын,
Нурларының тигез януын,
Гөлләремнең өскә калкуын,
Берөзлексез чәчәк атуын,
Чәчәк күреп йөзләр балкуын.
Җанда өметләрнең калкуын,
Сөюемнең тагын кайтуын,
Һәр кич саен кояш батуын,
Иртәгәсен таңның атуын
Көтәм.

## ТӨШЛӘРЕМӘ КЕР ӘЛЕ

Күңелемә бәйрәм булсын әле,
Төшләремә генә кер әле.
Төшләремдә синең белән булыйм,
Йөрәгемә гөлләр үр әле.

Тормышыма бер ямь булсын әле,
Төшләремә килеп кер әле.
Шатлыгымнан яшәрермен тагын
Такыялар үреп эл әле.

Төшләремә һәр көн кермәсәң дә,
Сирәк-мирәк булсын, кер әле.

Ике җанны тоташтырып шулай
Айлы төнне назга күм әле.

## КИТӘМ СИННӘН

Мин китәм бит синнән, сизәсеңме?!
Сине тынычлыкта калдырам.
Синең йөрәк нишләр, ансын белмим,
Ә мин соңгы шәмем яндырам.

Мин китәмен синнән, үпкәләмә!
Учагымны озак сакладым.
Кирәкмәсен үзем белгән килеш,
Сөюемне һаман акладым.

Китәм инде синең офыклардан,
Әле елап, әле җыр җырлап.
Йөрәгемдә калган наз-сөюне
Салкын җилгә бирми кочаклап.

## СӨЮ, МИҢА КИЛМӘ!

Сөю, миңа килмә!
Йөрәгемә тимә!
Кылдай күңелемне
Парә-парә телмә!
Ерактанрак йөре,
Күрми калыйм сине.
Акыллырак булыйм,
Булмыйм әле тиле,—

Дигән булып йөрим,
Йөрәктә ут яна.
Хәнҗәр кадаганчы,
Яраларын сана.

# I

*Көләрсең, көлдерер, шатландырырсың, Сөярсең, сөйгәнем, һәм сөйдерерсең.*
Дәрдмәнд

Сөйдерерсең, тәмам көйдерерсең,
Мал-мөлкәтен аның бөлдерерсең.

Фани дөньялыктан биздерерсең,
Ахырында адәм көлдерерсең.

## ӘЙТМӘ...

Юлларыма-алларыма чыгып,
Күзләремә төбәп карыйсың.
Ничә тапкыр инде, ничә тапкыр
Керфекләрем минем саныйсың.

Әйтмә миңа, синсез көям, диеп,
Хисләреңнән мине арала.
Әйтмә миңа, сине сөям, диеп,
Йөрәгемне минем яралап.

Күзләреңдә калсын йолдыз булып,
Изгеләрдән-изге ул сүзең,
Сүзләр белән вакламачы хисең,
Яратасың икән, бул түзем.

## БУЛСЫН ДИМЕН

Булсын димен, әйдә, борчуларым булсын,
Йөрәгемә сагышы да тулсын.
Бер борчусыз Җирдә тыныч яшәгәннәр
Тормыш-дәрья тәмен ничек тойсын.

Януларым, хәтта көюләрем булсын,
Йөрәгемә сөюе дә тулсын.
Мәхәббәттән янмаганнар, көймәгәннәр,
Ничек инде дөнья ямен белсен?!

## СҮНМӘС МӘХӘББӘТЕМ

Чирек гасыр буе янган йөрәк
Ничек янып бетми калган соң?!
Җәйге иртәләрдә сабырлыкны
Чык бөртекләреннән алгансың.

Вакыт-вакыт дөрләп янган чакта,
Чык бөртеген утка салгансың.
Мәхәббәтем, сүнмәс мәхәббәтем,
Мәңгелек җыр булып калгансың.

## СИНЕ УЙЛАП КҮҢЕЛЕМ ТУЛЫР

Таң атканда искән салмак җилләр
Чәчләреңнән сыйпап үтәрләр.
Сине истә тоткан берәү бар дип,
Колагыңа әйтеп китәрләр.

Кояш баеганда күккә кара,
Кояш нуры аша багармын.
Тылсымлы бер якты нур булып, мин
Һәрчак сине эзләп табармын.

Туп-тулы Ай күктә йөзгән чакта
Сагышларым артыр, шуны бел.
Җырласам да, көлсәм, еласам да,
Сине уйлап күңелем тулыр гел.

## СИРЕНЬ ИСЕ

Сирень исе...
Октябрьдә.
Җанга якын
Бер ис булып,
«Яшьлегеңнең
Хатирәсе
Мин идем бит»,—
Дигән кебек,
Ник томалый
Бүгенгемне?
Йөрәгемне
Дулкынлатып,
Күңелемне
Иләсләтеп,
Каян килгән
Бу вакытта,
Октябрьдә
Сирень исе?..

## ЙӨРӘГЕМДӘ ЧӘЧӘК ТАҖЫ КӨЯ...

Сагынуым сагышларга күчә,
Каеннарга шәүлә булып төшә.
Чараларын тапмый җаным кисә,
Сезнең яктан бары җилләр исә.

Изге хисем күңелемнән таша,
Зәңгәр күккә, болытларга аша.
Болытлардан яшь-яңгырлар коя,
Йөрәгемдә чәчәк тажы көя.

## И МӘХӘББӘТ...

И мәхәббәт, көчең чиксез синең,
Һәр таңымны тылсымлы иттең,
Һәр мизгелдән яхшылык көттем.

И мәхәббәт, көчең чиксез синең,
Хисләремне күккә ашырдың,
Ярларымнан чыгып ташыдым.

И мәхәббәт, көчең чиксез синең,
Йөрәгемне ничек ут иттең,
Янсам яныйм, синнән, юк, китмим.

## НИГӘ КИЛДЕҢ?

Нигә килдең инде көзләремә,
Яз-җәйләрем минем күрмәгәч.
Йөрәгемне нигә яраларга,
Нурга манып тасма үрмәгәч.

Көзләр — болай да бит сагыш йөзе,
Сагышларым нигә арттырдың?!
Күңел сандыгымда җаның тоеп,
Синсез ничә таңнар аттырдым.

Ник килергә көзләр белән бергә,
Ник утларга мине салырга?!
Күңел гөлләремә су сипмәгәч,
Ник чишмәдән сулар алырга?!

## КИТТЕ ДИМӘ

Китте димә, бетте димә,
Ярсулары үтте димә.
Яралары әле яңа,
Яраларга саксыз тимә.

Китте димә, бетте димә,
Кире кайтмас кабат димә.
Күңелем түрендә яткан
Истәлекләремә тимә!

## КҮЗЕМӘ КАРАМА

Күземә карама, язмышым юрама,
Ялгышлар күп булды юлымда.
Ышана язганмын ничәмә ел буе
Бәхетем, диеп, үз кулымда.

Күземә карама, бәхетем уала,
Күзгә-күз карашып торганда.
Кайларда йөрдең син, адашып-югалып,
Кыямда оямны корганда.

Күземә карама, намусым карала,
Күзләрең юллардан яздыра.
Тап-такыр түшәлгән юлларда абынып,
Кем инде оясын туздыра?!

ҖАН ТӘХЕТЕҢ

Мәхәббәтеңнең беренче
Алиһәсе булалмадым.
Күктән йолдыз санаганда,
Мине уйлап суламадың.
Ут-ялкыннар, дәрья-сулар
Аша туган мәхәббәтең —
Кадерлесе, сөеклесе,
Иң көтелгән җан тәхетең.

ЭЧТӘЛЕК

Җиләкле аланнар. *Әхсән Баянов* ...........

**Талгын җилләр шавы**

Тәрәзәмне ачам... ..........
Мең кат янарсың ..........
Гашыйк күзләр ..........
Азан ..........
Бирнә ..........
Җәйге алан ..........
Туңдым инде... ..........
Кашкарыйлар ..........
Яшьлегем ..........
Урамнарда кипкән яфрак исе ..........
Сагыш газабы да назлыдыр ..........
Безнең дәүләт ..........
И Җир шары... ..........
Бар байлыгым... ..........
Теләнчеләр ..........
Кара ла гына урман ..........
Мәскәү ягы ..........
Түзеп булмый ..........
Яз җиткәнен шуннан беләм ..........
Сәер айлар... май айлары ..........
Тыңла әле ..........
Моңым белән бәхетлемен ..........
Кайчагында... ..........
Җир-Анакай, кичер балаңны! ..........
Ялтырап китте урак ..........
Хәбәрләрең көтеп ..........
Янсаң — ян! ..........
Өмет итәм ..........
Уйлыйсың, уйланырсың... ..........
Тал агачы ..........
Кипкән җиләк ..........
Сагыш ..........
Белмим, нигә?! ..........
*** Тәрәзә белән көзге ..........
Әйтсәләр-сорасалар... ..........
Яратам ..........
Барма урманнарга... ..........
Елмаюым калсын ..........
*** Күзләр әле үтмәсә дә ..........
Кошлар минем сөю җырын җырлый ..........
Сөю ..........
Күрсен әле... ..........
Гасабилы газап ..........
Калыр кемдер... ..........
Әллә күрдем, әллә күрмәдем дә... ..........
Ачы балан ачы түгел ..........

Яктылыктан туя алмам ...................................
Ниятләгән хәят ................................................
Теләк ...............................................................
Ап-ак кына... ...................................................
Утлы күмер .....................................................
Ярат мине ........................................................
Кышкы кояш ....................................................
*** Җәйнең шундый кыска июнь төне .....
Таң җиле .........................................................
Гаҗәпләнәм ...................................................
Зират .................................................................
Сары яфрак ..................................................
Апа!.. ...............................................................
Булмыйдыр ул китеп... ..................................
Танымадың .....................................................
Еллар саныйм .................................................
*** Урмандагы карагайлар .........................
*** Галәмдә һәр кеше ................................
*** Юк белән бар янәшә килсә ..............
*** Туу-үлү арасында .................................
*** Шатлык килә ..........................................
*** Язмышым да минем катлы-катлы .......
Әни күчтәнәче ................................................
Эндәш миңа ....................................................
Рәнҗемә! ..........................................................
Кит .....................................................................
Көт .....................................................................
Кал .....................................................................
Күз сулышы ....................................................
**Шәм яктысы**

Юлга чыктым .................................................
Бәби, кызый, әни, әби ...................................
Юллар ..............................................................
Дуслар кирәк .................................................
Шигырьләр .....................................................
Көй агышы .....................................................
Шәмдәлләрдә утлар... ..................................
Гасыр башы, гасыр азагы... .......................
Киек Каз Юлы ................................................
Шулай яратам ...............................................
Хатын-кызның яшен сорамыйлар ...............
Диңгез ............................................................
Агымсу ...........................................................
Таулар .............................................................
Әйтмәгезче юатыр сүз .................................
Беренче кырау ...............................................
Ике дөнья арасы ...........................................
Бөдрә талым ..................................................
Кипкән букет .................................................
Әбиләр чуагы ................................................
Сабырмы соң йөрәк? ...................................
Быелгы язларның шаукымы .........................
Күтәралган кадәр .........................................
Замана ...........................................................
Бакча ..............................................................
Сагыш... ............................................................
Казлар китте... ................................................
Күл йөрәге ......................................................
Кар исе ............................................................

Булмады... .......................................................
Җаным һаман унҗидедә ..............................
Бары тик тиң иткәнгә... ..................................
*** Февраль киче .........................................
*** Шәһәр йоклый ........................................
Шәм яктысы ......................................................
*** Кыр казының һаваларда .....................
Сыздырып тарт әле кураеңны ....................
Уй .....................................................................
Сынмадым .......................................................
Моң ....................................................................
Кышкы урман ..................................................
Язлар саен .......................................................
*** Бу дөньяда үкенүләр азмы икән ........
*** Табар өчен югалтабыз .......................
*** Кояш  булмаганда ................................
*** Кышкы иртә .............................................
*** Карурманнарда .....................................
*** Караңгыдан яктылыкны ........................
*** Карап калдым эзләреңә ....................
Сибелде чәчләрем ........................................
**Мәхәббәт елы**

Юк инде... ........................................................
Хатлар юллыйм .............................................
Төнге тынлык ..................................................
Җаным тыныч түгел .......................................
Туй көннәре ...................................................
Нәркис чәчәк ..................................................
Нишләрсең? ....................................................
Бәлки... ...............................................................
Язмыш белән уйнама ...................................
Киттең... ...........................................................
Сихри очкын ...................................................
Балачак .............................................................
Эзләдем ............................................................
Сулар тындылар бугай .................................
Сагынуның чиге була микән?! ....................
Яңгыр исе ........................................................
*** Белсәң иде .............................................
*** Күпме газап чигәремне белсәм .........
*** Кил, өшегән җаныңны мин җылытырмын ......................................................................
Төн карасын ерып, күңелемә .....................
Барыбер яратырсың .....................................
*** Күңелемә моңнар булып кердең .......
Оныттыңмы? ....................................................
Килереңне көттем ........................................
Кояш булып нурга чумар идем .................
Синсез көям ...................................................
Көтәм ...............................................................
Төшләремә кер әле .......................................
Китәм синнән ..................................................
Сөю, миңа килмә! ..........................................
*** Сөйдерерсең, тәмам көйдерерсең ...
Әйтмә... ...........................................................
Булсын димен .................................................
Сүнмәс мәхәббәтем ......................................
Сине уйлап күңелем тулыр ........................
Сирень исе .....................................................
Йөрәгемдә чәчәк тажы көя... .....................
И мәхәббәт... .................................................

Нигә килдең? ..................................................
Китте димә ........................................................
Күземә карама ..............................................
Җан тәхетең ...................................................

Литературно-художественное издание

**Мухиярова Разина Хайбрахмановна**

ВЕЧНОЕ ГОРЕНИЕ

Стихи

*(на татарском языке)*

Редакторы *Н. Р. Акмалов*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Корректоры *А. М. Дәминова*
Компьютерда биткә салучысы *Л. Г. Зиргизова*

Нәшриятка 183 нче номерлы лицензия
1997 елның 7 апрелендә бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 07.02.02. Форматы 70ә84$^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе.
Гарнитурасы «Футурис». Офсет басма.
Шартлы басма табагы 4,9.
Нәшер-хисап табагы 3,45.
Тиражы 1000 д. Заказ Б-7.

«Мәгариф» нәшрияты.
420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Издательство «Магариф».
420111. Казань, ул. Баумана, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
Http://magarif.kazan.ru/
E-mail: magarif@mail.ru
ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.